**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Уразаевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Энгельса, д..65, с.Уразаево, 423330
Тел. (8-85592) 43555, факс (8-85592) 43555

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты**

Энгельс урамы, 65, Уразай авылы, 423330
Тел. (8-85592) 43555, факс (8-85592) 43555

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

от 31 гыйнвар 2020 года — № 1

2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыны «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 18 май, 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020т елның 29 гыйнварындагы 61 нче номерлы «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» карары нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6 124,86 (алты мең йөз егерме дүрт сум, 86 тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 5 апреленнән 24 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» карары үз көчен югалткан дип санарга.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http// pravo. tatarstan. ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatarstan. ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: А.М.Шәрифуллина

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитет карарына 1 нче кушымта

«31 » гыйнвар 2020 № 1

**2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең хакы**

| № | **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда** |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 148,86 |
| 2. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 863,00 |
| 3. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 113,00 |
| 4. | **Барлыгы** | **6 124,86** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитет карарына 2 нче кушымта
«31 » гыйнвар 2020 № 1

**2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең хакы**

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Кәфенләү | 841,42 |
| 2. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 307,00 |
| 3. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 863,44 |
| 4. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 113,00 |
| **5.** | **Барлыгы** | **6 124,86** |